ГЛАВА ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН БАШЛЫГЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.06.2026 № 56

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башлыгының «Муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленә башка түләүле эшне башкару нияте турында хәбәр итү тәртибен раслау хакында» 2016 елның 27 июлендәге 89 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы прокуратурасының 2026 елның 13 маендагы 02-08-01 номерлы протесты нигезендә, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга таянып

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башлыгының 2016 елның 27 июлендәге 89 номерлы карары белән расланган «Муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан яллаучы (эш бирүче) вәкиленә башка түләүле эшне башкару нияте турында хәбәр итү тәртибе»нә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 8 пунктны түбәндәге җөмлә белән тулыландырырга:

«Яллаучы (эш бирүче) вәкиле хәбәрнамәне 10 эш көне дәвамында карый»;

1.2. түбәндәге эчтәлекле10.1 пункты белән тулыландырырга:

«10.1. Комиссиядән хәбәрнамәне карау нәтиҗәләрен алгач, яллаучы (эш бирүче) вәкиле түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) муниципаль хезмәткәргә түләүле башка эш башкаруга ризалык бирергә;

2) муниципаль хезмәткәргә түләүле башка эшне башкаруга рөхсәт бирүдән баш тартырга.».

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырып игълан итәргә.

Р.Ф.Хисамутдинов